ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“10” ноябрь 2025 ел Борды авылы № 13

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең Бордыбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Борды авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл жирлеге Советынын 07.11.2019 елнын 51/1 номерлы карары белэн “Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл жирлеге составына керуче торак пунктларда гражданнар жыенын эзерлэу һәм утксэру тэртибе турында “Нигезлэмэне раслау хакында”

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең Бордыбаш авылында 2025 елның 21 ноябрендә 10.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Борды авыл җирлегенең Бордыбаш авылы территориясендә 2026 елда балигъ булган, Борды авыл җирлегенең Бордыбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йоз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йоз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Борды авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Бордыбаш авылының Үзәк урамындагы суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау)

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Бордыбаш авылы, Узэк урамы, 83 йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Борды авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Абдульманова